Reviews

Бәяләмә һәм күзәтүләр

Рецензии и обзоры

DOI: 10.26907/2311-2042-2021-16-1-188-193

# REVIEW OF THE SERIES "FOLK ART OF THE BASHKORTOSTAN TATARS" (КAZAN: IYALI, 2021)

**Liliya Khatipovna Muhammetzyanova,**
G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art, Tatarstan Academy of Sciences,
12 K. Marx Str., Kazan, 420111, Russian Federation,
lilmuhat@mail.ru.

The article reviews the series *"Folk Art of the Tatars of Bashkortostan"*, which was published in Kazan in 2021. The reviewer notes the richness and diversity of the collected folklore material, as well as the accuracy of scientific tools. The article emphasizes the value and significance of this academic series in the cultural life of the two Turkic republics.

**Key words**: Tatars, Tatar folklore, Republic of Bashkortostan, Republic of Tatarstan.

Only one-quarter of the Tatar population lives in Tatarstan. The remaining three-quarters reside in different parts of the Russian Federation and around the world. According to the 2010 Census, more than 1 million Tatars live in the Republic of Bashkortostan alone, just east of Tatarstan. In terms of the number of Tatars here, they are the third largest ethnic group, which makes up 24.78% of the population in this republic. Evidently, the spiritual heritage of representatives of the Tatar ethnic group, living on the territory of Bashkortostan, is an area of great interest for researchers, as the identification and study of their heritage is one of the most important tasks in Tatar Studies.

The ethnogenesis, historical, cultural and linguistic features of the Tatars, living in the territory of the present-day Republic of Bashkortostan, have been sufficiently studied, and the results of their most important works have been published. Nevertheless, there are still certain disputes over the issue concerning the national self-determination of the Tatar-speaking population. In this regard, it is important to discuss the folklore of the Tatars who have long been a part of the Republic of Bashkortostan's local population and to review the history and current state of the corpus and research into Tatar folklore in this area.

The scholars from Kazan Research Centers, in particular the G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art of the Tatarstan Academy of Sciences, are carrying out a very thorough study on our compatriots, living in the territory of Bashkortostan: the Institute organized a comprehensive scientific expedition to the Sterlibashevsky district of Bashkortostan in 2017, which led to the preparation and publication of the series "Our National and Cultural Heritage. Treasures of Scientific Expeditions", consisting of two parts.

Another step in the study of the spiritual wealth and the disclosure of widespread folk art among the Tatars, living in the territory of Bashkortostan, is the publication of the academic series "Folk Art of the Tatars of Bashkortostan", consisting of three books [Bashkortstan Tatarlary folklory. Kənbatysh həm kəniak-kənbatysh raionnar], [Bashkortstan Tatarlary folklory. Təniak həm təniak-kənchygysh raionnar], [Bashkortstan Tatarlary folklory. Yzək həm təniak-kənbatysh raionnar]. The creator of the series, the author of its foreword article and commentary is Ildus Fazletdinov, Candidate of Philology, Associate Professor. The scientific editor of the series is Prof. Kim Minnullin, Doctor of Philology.

All three books are distinguished by their deep, broad and rich content. The structure of the series is built as a geographical arrangement of different folklore genres, recorded in the territory of Bashkortostan: the history of villages, rivayats, legends, myths, sayings, anecdotes, fairy tales, bayts, munajats, folk songs, aphoristic genres, rituals and children's folklore. The foreword, which the first book begins with, the cover and the title pages specify the districts each book refers to. The first book covers the western and southwestern districts, the second book includes the north and northeastern parts, and the third book describes the central and northwestern territories.

In compiling this series on Tatar folklore in Bashkortostan, the author primarily aims to conduct a comparative analysis of the local features, characterizing Tatar folklore. The foreword of the book, the principles of structure, the richness of the collected material and genres indicate that I. Fazletdinov distinguishes Tatar folklore as a single system. Moreover, this work aims to preserve the integrity of the Tatar people in today's complicated socio-political situation and prevent the nation from splitting apart.

It is important to mention that the folklore samples, given in these three volumes, preserve local language characteristics of the population. As mentioned above, the content of the books is arranged according to the geographical principle.

The first book of the series "Folk Art of the Tatars of Bashkortostan" includes the folklore of the Tatars, living in the western and southwestern regions of Bashkortostan. These include: the Bizhbulyakskiy, Yermekeyevo, Tuymazy, Buzdyak, Alsheyevo, Miyakinskiy and Sharan districts. They used to be the lands of the ancient Kazan Khanate. From the linguistic point of view, the speech of the Tatars in this region does not differ from the norms of the Tatar literary language. The materials, contained in this volume, increase our attention to the history of the Tatars through the preservation and promotion of the Tatars' ethnic integrity and their folk art. [Bashkortstan Tatarlary folklory. Kənbatysh həm kəniak-kənbatysh raionnar].

The second book describes the folklore of the Tatars, living in the regions of the north and northeast of Bashkortostan. This part includes folklore materials collected in the Askinsky, Karaidel, Kiginsky, Krasnokamsky, Mechetlinsky, Tatyshlinsky, Yanaulsky, partially Nurimanovsky and Uchalinsky districts. It is important to note that the Askinsky, Karaidel, Kiginsky, Nurimanovsky, Mechetlinsky and Uchalinsky districts are ethnically diverse regions. Therefore, this book's focal point is how different ethnic traditions, based on historical evidence, come together and influence each other. The volume includes folklore works, collected in the villages with the overwhelming number of Tatar residents. [Bashkortstan Tatarlary folklory. Təniak həm təniak-kənchygysh raionnar].

The third book includes folklore works of Tatars, living in the central and north-western regions of Bashkortostan. These include such districts of Bashkortostan as the Chekmagushevsky, Ilishevsky, Bakalinsky, Dyurtyulinsky, Burayevsky, Baltasinsky, Kushnarenkovsky and Chishminsky ones. In terms of language, these areas are mainly monoethnic and the majority of the population are Tatars. The folklore samples, included in the third book, are arranged in the same way as in other volumes, taking into account the principles of the genre. [Bashkortstan Tatarlary folklory. Yzək həm təniak-kənbatysh raionnar].

In each volume, every text, in relation to a particular sample, contains indications as to when, where and by whom the given material was recorded, i.e. it is properly registered. This series carries an important message aiming to identify and popularize the national and cultural heritage of the Tatars, living in Bashkortostan. Folklore has both a literary value and historical significance, as it tells the story of the people's own life experiences. Tales, legends and myths belong to the most important sources in the study of the most ancient history of any ethnic group. The genres of folk art reflect the philosophy of life, experience, historical past and the memory of previous generations. The materials, included in each book of the series, confirm the idea of the inseparable Tatar nation. This work highlights the crucial role that folk art plays in our history being the evidence of our Tatarness.

If history shows that the Tatars have lived in the Eurasian steppe since ancient times, oral folk art reinforces this fact, makes it more convincing reflecting the gradual development of our nation. The Tatars, living in the territory of Bashkortostan, have the same types and genres of folklore as known in the national folklore; moreover, the repertoire of folk art here is similar to the commonly known Tatar folklore. This fact can be confirmed by the materials included in the third volume of "Folk Art of the Tatars of Bashkortostan".

We live in an era when increased attention is paid to the historical, spiritual and cultural monuments of our people. The role of oral traditions in clarifying new issues of the time is indeed enormous. Going back to our roots to find out when our compatriots settled in the lands of modern Bashkortostan and made it their Homeland, identifying the features of their everyday life, examining the historical events that changed their lives, their relationships with neighboring ethnic groups, local terms for natural assets – these and other important facts and phenomena, related to oral traditions and included in the reviewed series, are all monuments recorded from our compatriots, living in the territory of Bashkortostan. Each of them can shed light on many issues in different aspects, helping to more accurately and fully restore the history of our people. "Folk Art of the Tatars of Bashkortostan" series, based on the territorial principle, is a clear example of how often oral traditions can reflect what the material and non-material historical sources cannot describe.

**References**

*Bashkortstan Tatarlary folklory. Kənbatysh həm kəniak-kənbatysh raionnar* (2021) [Tatar Folklore of Bashkortostan. West and Southwestern Districts]. Təzүche həm alatmalar - I. K. Fazletdinov. 312 p. Kazan, TAhSI. (In Tatar)

*Bashkortstan Tatarlary folklory. Təniak həm təniak-kənchygysh raionnar* (2021) [Tatar Folklore of Bashkortostan. North and Northeastern Districts]. Təzүche həm alatmalar - I. K. Fazletdinov. 296 p. Kazan, TAhSI. (In Tatar)

*Bashkortstan Tatarlary folklory. Yzək həm təniak-kənbatysh raionnar* (2021) [Tatar Folklore of Bashkortostan. Central and Northwestern Districts]. Təzүche həm alatmalar - I. K. Fazletdinov. 304 p. Kazan, TAhSI. (In Tatar)

*Milli-medəni mirasybyz: Bashkortostan Tatarlary* (2021) [Our National and Cultural Heritage: Tatars of Bashkortostan]. Stərlebash. 1 nche kisək. 2 nche basma. 440 p. Kazan. (In Tatar)

*Milli-medəni mirasybyz: Bashkortostan Tatarlary* (2021) [Our National and Cultural Heritage: Tatars of Bashkortostan]. Stərlebash. 2 nche kisək. 2 nche basma. 448 p. Kazan. (In Tatar)

# "БАШКОРТСТАН ТАТАРЛАРЫ ФОЛЬКЛОРЫ" (КАЗАН: ТӘҺСИ, 2021) ҖЫЕНТЫКЛАРЫНА БӘЯЛӘМӘ

**Лилия Хатип кызы Мөхәммәтҗанова,**
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты,
Россия, 420111, Казан ш., К. Маркс ур., 12 нче йорт,
lilmuhat@mail.ru.

Мәкалә 2021 елда Казанда нәшер ителгән "Башкортстан татарлары фольклоры" җыентыкларына бәяләмә буларак язылган. Рецензент тупланган фольклор материалының байлыгын һәм төрлелеген, фәнни инструментарийның тикшерелгәнлеген билгели. Мәкаләдә бу академик басманың ике төрки халыкның мәдәни тормышында кыйммәте һәм әһәмияте ассызыклана.

**Төп төшенчәләр:** татарлар, татар фольклоры, Башкортстан Республикасы, Татарстан Республикасы.

Татар халкының дүрттән бер өлеше генә Татарстанда яши. Калган өлеше Россия Федерациясенең һәм дөньяның төрле почмакларында гомер кичерә. 2010 елгы халык исәбен алу нәтиҗәләре буенча, Татарстаннан көнчыгышта урнашкан Башкортстан Республикасында гына да 1 миллионнан артык татар яшәгәнлеге мәгълүм. Сан ягыннан биредә татарлар өченче урынны алып тора, бу исә республикада яшәүче халыкның 24,78 проценты дигән сүз. Табигый, Башкортстан территориясендә көн иткән татар халкының рухи мирасы галимнәрдә зур кызыксыну уята һәм бу байлыкны барлап, туплап,

гыйльми нигездә өйрәнү гуманитар фәндә әһәмиятле бурычларның берсе булып тора.

Хәзерге Башкортстан Республикасында гомер иткән татарларның этногенезы, тарихи, мәдәни һәм тел үзенчәлекләре галимнәр тарафыннан шактый өйрәнелгән. Шулай булса да, биредәге татар телле халыкның милли үзбилгеләнеше мәсьәләсендә бәхәсләр әлегә кадәр тынганы юк. Бу җәһәттән Башкортстан төбәгендә борын-борыннан җирле халыкның зур өлешен тәшкил иткән татарларның фольклор әсәрләре турында фикер алышу; әлеге ареалда татар халык авыз иҗатын җыю һәм өйрәнү тарихына, татар фольклорының хәзерге торышына күзәтү ясау бүгенге көндә актуаль мәсьәләләрдән санала.

Башкортстанда яшәүче милләттәшләребезне өйрәнү юнәлешендә Казан фәнни үзәкләре, аерым алганда Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре шактый эш алып бара. Әйтик, 2017 елда Башкортстанның Стәрлебаш районына комплекслы фәнни экспедиция оештырылып, аның нәтиҗәләренең «Милли-мәдәни мирасыбыз. Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендә ике кисәктән торган китапларның басылып чыгуы шушы омтылышның ачык мисалы булып тора [Милли-мәдәни мирасыбыз, 1 нче кисәк], [Милли-мәдәни мирасыбыз, 2 нче кисәк].

1921 елда “Башкортстан татарлары фольклоры” дип аталган өч китаптан торган җыентыкның басылып чыгуы Башкортстан төбәгендәге татарларның рухи байлыгын, аеруча киң таралыш алган халык иҗатын ачу бу юнәлештә тагын бер мөһим адым булды [Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш районнар], [Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк һәм төньяк-көнчыгыш районнар], [Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк һәм төньяк-көнбатыш районнар]. Томнарны төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы - И. К. Фазлетдинов, фәнни редакторы - К. М. Миңнуллин.

Китаплар тирән, шактый киң һәм бай эчтәлекле булулары белән игътибарны җәлеп итә. Томнарның төзелеше Башкортстан төбәге татарларыннан язып алынган фольклор жанрларыннан авыл тарихларын, риваятьләрне, легендаларны, миф, сөйләк, мәзәк, экият, бәет үрнәкләрен, мөнәҗәтләр, халык җырлары, афористик жанрларны, йола һәм балалар фольклорын географик принципта урнаштырудан гыйбарәт. Беренче китапны ачып җибәргән “Кереш”тә, тышлыкларда, титул битләрендәге резюмеда һәр томның кайсы районнарны иңләве ачыклана. Беренче томда – көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш районнар, икенче томда – төньяк һәм төньяк-көнчыгыш, ә өченче томда исә – үзәк һәм төньяк-көнбатыш районнар.

Төзүче-автор, Башкортстан татарлары халык авыз иҗатына багышланган әлеге җыентыкларны эшләгәндә, беренче чиратта, тикшеренүчеләр өчен татар фольклорының локаль үзенчәлекләрен чагыштырма планда анализлау мөмкинлеген тудыру максатын алга куйган. И. Фазлетдинов татар фольклорын бербөтен система буларак өйрәнә һәм бәяли. Шул ук вакытта әлеге хезмәт бүгенге катлаулы иҗтимагый-сәяси вазгыятьтә татар халкының бөтенлеген саклау, аны төрле тарафларга тарткалауга-бүлгәләүгә юл куймауны да күздә тота.

Шунысын да искәртү мөһим: өч томлыкта фольклор үрнәкләре халыкның җирле тел үзенчәлекләрен саклап тәкъдим ителә. Алда әйтелгәнчә, китапны төзегәндә, географик принцип нигез итеп алынган. Бу бүленеш, шактый дәрәҗәдә шартлы булса да, гамәли күзлектән караганда һәм татарлар компактлы яши торган аерым бер территориядә таралган фольклор үрнәкләренә игътибарны юнәлтү җәһәтеннән уңышлы.

“Башкортстан татарлары фольклоры” китапларының беренчесенә Башкортстан көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш районнары татарларының фольклор әсәрләре кертелгән. Бу төбәккә Казан ханлыгы җирләрендә урнашкан Бишбүләк, Ярмәкәй, Туймазы, Бүздәк, Әлшәй, Миякә, Шаран районнары керә. Тел җәһәтеннән караганда да, бу як татарларының сөйләше татар әдәби теле нормаларыннан бөтенләй аерылмый. Томдагы материаллар татарларның этник бөтенлеген, халык иҗаты әсәрләрен саклау һәм пропагандалау аша милли тарихка игътибарны көчәйтә [Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш районнар].

Икенче китапның эчтәлеген Башкортстанның төньяк һәм төньяк-көнчыгышындагы этник яктан катнаш булган Аскын, Караидел, Кыйгы, Краснокама, Мәчетле, Тәтешле, Яңавыл, өлешчә Нуриман, Учалы районнарында җыелган фольклор материаллары тәшкил итә. Шуңа күрә китапта төрле этник традицияләрнең тарихи закончалыкларына нигезләнеп, үрелеп килүенә һәм бер-берсенә йогынты ясавына әһәмият бирелгән. Томга татарлар аеруча

күпләп яшәгән авыллардан җыелган фольклор әсәрләре генә кертелгән [Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк һәм төньяк-көнчыгыш районнар].

Башкортстанның үзәк һәм төньяк-көнбатыш төбәгендәге Чакмагыш, Илеш, Бакалы, Дүртөйле, Борай, Балтач, Кушнаренко, Чишмә районнарында гомер иткән татарларның фольклор әсәрләре өченче китапка кертелгән. Бу төбәктә, тел ягыннан, нигездә, моноэтник, татарлар күпчелекне тәшкил итә. Бу томдагы фольклор үрнәкләре дә башкаларындагы структура буенча, жанр принципларын исәпкә алып урнаштырылган [Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк һәм төньяк-көнбатыш районнар].

Һәр томдагы аерым текстның кайчан, кайсы авылда кемнән, кем тарафыннан язып алынуы күрсәтелгән, ягъни томнардагы материал төгәл паспортланган. Бу китаплар – Башкортстанда яшәүче татарларның милли-мәдәни мирасын барлап, аны халыкка тәкъдим итүдә җитди хезмәт. Халыкның үз башыннан кичергән вакыйгалары турында сөйләгәнгә күрә, фольклор әсәрләре әдәби кыйммәткә дә, тарихи әһәмияткә дә ия. Риваятьләр, легендалар, мифлар – теләсә кайсы халыкның иң борынгы тарихын өйрәнүдә мөһим чыганакларның берсе. Халык иҗаты жанрларында элгәрге буыннарның тормыш фәлсәфәсе, тәҗрибәсе, тарихи үткәне, хәтере чагылыш таба. Китапның һәр томындагы материал татар милләтенең бердәмлеге идеясен раслый. Алар халык иҗаты юнәлешенең дә, һичшиксез, татарлыкны дәлилләвенә басым ясый.

Тарих татарларның Евразия далаларында бик борынгы чорлардан ук яшәп-көн итеп килүен дәлилле икән, халыкның авыз иҗаты әсәрләре дә шушы хакыйкатьне көчәйтеп, исбатлап кына калмый, ә шул ук тарихның эзлекле рәвештә үсеш-үзгәрешен дә чагылдыра. Башкортстан төбәгендә гомер иткән татарлар фольклорына да барлык авыз иҗаты төрләре һәм жанрлары хас, халык иҗатының биредәге репертуары гомумтатар фольклорын колачлый. Бу фикер “Башкортстан татарлары фольклоры”ның 3 томлыгына кергән материалларга күзәтү белән раслана.

Халкыбызның тарихына, рухи һәм мәдәни ядкярләрен барлауга игътибар көчәйгән чорда яшибез. Заман тудырган яңа сорауларга ачыклык кертүдә халык авыз иҗаты әсәрләренең роле, чыннан да, бик зур. Тарих төпкеленә төшеп, хәзерге Башкортстан җирләренең кайсы дәверләрдән милләттәшләребез өчен Ватан булуын ачыклау, мондагы татарларның төрле өлкәләргә карый торган борын-борыннан килгән яшәү-тормыш итү үзенчәлекләрен билгеләү, тарихи вакыйгаларның алар тормышындагы ролен тикшерү, күрше халыклар белән мөнәсәбәтләре, җир-су атамаларының этимологиясе кебек мәсьәләләрне өйрәнүгә бу территориядә яшәгән милләттәшләрдән язып алынган ядкярләр үзләреннән зур өлеш кертә, халкыбыз тарихын төгәлрәк, тулырак торгызырга булыша. Территориаль принципны эченә алган “Башкортстан татарлары фольклоры” җыентыклары – матди һәм матди булмаган тарихи чыганаклар сөйләп бетерә алмаганны күп вакыт халыкның авыз иҗаты әсәрләре бәян итә алуның ачык мисалы.

**Әдәбият**


*Bashkortstan Tatarlary folklory. Kənbatysh həm kəniak-kənbatysh raionnar* (2021) [Tatar Folklore of Bashkortostan. West and Southwestern Districts]. Təzүche həm alatmalar - I. K. Fazletdinov. 312 p. Kazan, TAҺSI. (In Tatar)

*Bashkortstan Tatarlary folklory. Təniak həm təniak-kənchygysh raionnar* (2021) [Tatar Folklore of Bashkortostan. North and Northeastern Districts]. Təzүche həm alatmalar - I. K. Fazletdinov. 296 p. Kazan, TAҺSI. (In Tatar)

*Bashkortstan Tatarlary folklory. Yzək həm təniak-kənbatysh raionnar* (2021) [Tatar Folklore of Bashkortostan. Central and Northwestern Districts]. Təzүche həm alatmalar - I. K. Fazletdinov. 304 p. Kazan, TAҺSI. (In Tatar)

*Milli-medəni mirasybyz: Bashkortostan Tatarlary* (2021) [Our National and Cultural Heritage: Tatars of Bashkortostan]. Stərlebash. 1 nche kisək. 2 nche basma. 440 p. Kazan. (In Tatar)

*Milli-medəni mirasybyz: Bashkortostan Tatarlary* (2021) [Our National and Cultural Heritage: Tatars of Bashkortostan]. Stərlebash. 2 nche kisək. 2 nche basma. 448 p. Kazan. (In Tatar)

# РЕЦЕНЗИЯ НА КНИГИ ИЗ СЕРИИ «ФОЛЬКЛОР ТАТАР БАШКОРТОСТАНА» (КАЗАНЬ: ИЯЛИ, 2021)

**Лилия Хатиповна Мухаметзянова,**
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ,
Россия, 420111, г. Казань, ул. Карла Маркса, д. 12,
lilmuhat@mail.ru.

Статья носит характер рецензии на книги из серии «Фольклор татар Башкортостана», увидевшей свет в Казани в 2021 году. Рецензент отмечает богатство и разнообразие собранного фольклорного материала, выверенность научного инструментария. В статье подчеркивается ценность и значение этого академического сборника в культурной жизни двух тюркских республик.

**Ключевые слова:** татары, татарский фольклор, Республика Башкортостан, Республика Татарстан.